Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы КАРАРЫ

2024 елның 9 декабре № 226

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 18 апрелендәге 36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 8 августындагы 232-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә , Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 18 апрелендәге 36 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегендә:

1.1.1. 9 өлешнең 2 пунктында «муниципаль районның сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.2. 13 өлешнең 1 пунктында:

1 пунктчаның «в» өлешендә «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җирле үзидарә органында ул муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән йә федераль законнарда башкасы каралмаган булса, турыдан-туры аңа буйсынган яисә аңа буйсынган өченче зат эшләре буенча вәкил булырга;»;

4 пунктчада «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктчада «сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.3. Нигезләмәнең 13.1 өлешендәге 4 пунктында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Нигезләмәнең 4 бүлегендә:

1.2.1. 15 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;

1.2.2. 18 өлешнең 1 пунктында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Т. Гыйниятовка йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы урынбасары ,
Кама Тамагы районы муниципаль район
Советы рәисе урынбасары И.Т. Гыйниятов